Бүгенге санда:



**Нурлат гаиләсе 6 ятим баланы үзенә сыендырган. 2 бит**


# Дуслык

Дружба

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Җомга 3 апрель 2015 ел

№ 24 (10553)


**4 апрельгә һава торышы:** болытлы һава, карлы яңгыр булуы мөмкин, җил көньяк-көнчыгыштан 4 м/с; температура көндез +1°С, төнлә 0°С

ХӘБӘРЛӘРЕГЕЗНЕ КӨТӘБЕЗ

Телефоннар: 2-36-13, 2-36-20.

*Абзац-информ*

### «НУРЛАТ-ТВ» ҖИҢҮЛӘР ЯУЛЫЙ

Елның тәүге уңышына алар "ТРда энергия саклау һәм энергетик нәтиҗәлелекне күтәрү" дәүләт программасын тормышка ашыруны пропагандалау буенча массакүләм мәгълүмат чаралары конкурсында катнашып ирештеләр. "Иң яхшы телекомпания" номинациясендә Дипломны аларга кичә ТР Хөкүмәте утырышында Премьер-Министр урынбасары Равил Зарипов тапшырды.

### ЮБИЛЕЙЛАР ЕЛЫ УҢЫШЫ

Бөтенроссия Сукырлар оешмасының Нурлат районара җәмгыяте командасы Алабугада узган республика ярышларыннан II урын белән кайтты. Бөтенроссия сукырлар җәмгыятенең – 90, Җиңүнең 70 еллыгына багышланган чарада җәмгыять әгъзалары Виталий Говоров, Камил Хәсәншин һәм Римма Баянова катнашканнар.

### АЗАТНЫ ФИНАЛ КӨТӘ

"Ел тәрбиячесе-2015" республика конкурсының финалында район данын "Камыр Батыр" балалар бакчасы тәрбиячесе Азат Ягъфәров яклаячак. Зона турында җиңү яулаган педагог-тәрбияче 7-8 апрельдә Казанда узачак финалда төсләр белән дәвалау темасына чыгыш ясачак.

### ОСТАЛАРДАН МАСТЕР-КЛАСС

"Ел укытучысы" республика конкурсының "Ел сыйныф җитәкчесе" номинациясендә гимназиядән Нина Авдушкина, ә "Ел педагог-психологы" номинациясендә "Доверие" үзәге педагог-психологы Елена Исаева үз осталыкларын республика этабында тәкъдим итәчәк. Районның ике иң яхшы педагогы – зона этабы җиңүчеләре педагоглык осталыгы турында сөйләүдән тыш, коллегаларына мастер-класс та күрсәтәчәк.

### АВТОТРАНСПОРТЧЫЛАР БҮЛӘГЕ

Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан "Нурлат АТП"сы җәмгыяте үз акциясен тәкъдим итә. 5–10 майда Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм тыл хезмәтчәннәрен шәһәр автобусларында түләүсез йөртү оештырылачак. Акция барышында әлеге категория гражданнарга таныклыкларын үзләре белән йөртү шарт.

## Киләчәккә ныклы нигез



Сирень Сәмәрханова фотосы

«РЕСПЕКТ СП»ның РЕЗИНА ЭШКӘРТҮ БУЕНЧА ОПЕРАТОРЫ НИКОЛАЙ ЗАХАРОВ ҺӘМ МАСТЕР МАРАТ МИНЗАРИПОВ ЯҢА ПРОИЗВОДСТВОНЫ КЫСКА ВАКЫТ ЭЧЕНДӘ ҮЗЛӘШТЕРГӘН

**Районда төрле милек формасындагы 10лап мәйданчык тулы инфраструктурага ия. Һәм хәзер кызыксынган яклар белән конструктив хезмәттәшлекне максималь нәтиҗәле итеп төзү буенча эш җәелдерелгән.**

Икътисадый кризис булуга карамастан, безнең район яши һәм үсә, дип әйтергә була. Күптән түгел генә иске шиннарны кабат эшкәртү һәм утильләштерү буенча цех эшли башлады. "Респект СП"да таушалган резинага куланылыш табылу белән беррәттән 18 кешегә эш урыны да булдырылды. Инвестицияләр җәлеп итү исә – район җитәкчелеге бу юнәлештә эшләүне үзенең төп бурычларыннан саный – төрле өлкәләрдә тулаем җитештерү ачарга мөмкинлек бирәчәк. Мәсәлән, быел шәһәрдә 10 млн. сумлык инвестиция хисабына тәүлегенә 40 кубометр газопенобетон җитештерү буенча цех эшләтеп җибәрү күздә тотыла. "Престижстрой" предприятиесе бу төзелеш материалын ясау өчен җиһазларын да сатып алган инде.

- Хәзер сынап карау өчен һава торышының җайлануын көтәбез, - ди аның җитәкчесе Рәфис Шәмсуров.

Нурлатның потенциалы инвесторларны җәлеп итәрлек. Февраль азагында Төркия делегациясенең яңа сәнәгый мәйданчыкларны өйрәнү һәм аларга инвестицияләр кертү максатыннан Нурлатка визиты да шул хакта сөйли. Мәсәлән, Төрнәс спирт заводында Төркия кунаклары складлар, бөртек саклагычлар, җайланмаларның эш хәлендә булуына игътибар иттеләр. Әлбәттә, аларны район башлыгының эшне башлаганда ташламалы шартлар тәкъдим итүе дә кызыксындырды. Хәзер 4 инвестор әлеге мәйданчыкны үз җитештерүләрен үстерү өчен вариант буларак карый. Инвесторларның инвестицияләрен Нурлат районына кертергә җыенулары барыннан да элек аларның Татарстанга һәм аның лидерына ышанычы турында сөйли. Чөнки илдәге катлаулы икътисадый шартларга да карамастан, Рөстәм Миннехановның стратегиясе республикага инвестицияләр җәлеп итүгә юнәлтелгән. Бу юнәлештәге заманча эш формаларын Нурлатта беренче көннәреннән үк район башлыгы Равил Кузюров та куллана башлады. Чөнки инвестицияләр җәлеп итү халыкның яшәү дәрәҗәсен, муллыгын, җирлекнең инфраструктурасын яхшырту белән бергә социаль мәсьәләләрне хәл итү, яңа эш урыннары булдыру да.

**Ахыры 2нче биттә.**

*"Алабуга" махсус икътисади зонасында "Хаят Кимья" заводы ачылуы турында "Атна вакыйгалары"нда укыгыз.*

## «Ярдәм буласына шикләнмәгез»

**Районда 1412 кече эшмәкәрлек субъектының 356сы – икътисади актив микропредприятиеләр, 1056сы – шәхси эшмәкәрләр. Җирле эшкуарларның сишәмбе көнне республика вәкилләре белән узган очрашуында шундый саннар китерелде.**

Бу чара шәхси эшмәкәрләргә, кече һәм урта бизнес предприятие җитәкчеләренә, крестьян-фермерлык хуҗалыклары башлыкларына мәгълүмати-консультатив ярдәм күрсәтү йөзеннән оештырылды. Очрашуны район башлыгы Равил Кузюров ачып җибәрде, һәм мондый чараларның файдалылыгын да билгеләп үтте.

Иң элек республика Икътисад министрлыгының эшмәкәрләргә ярдәм итү Департаменты начальнигы урынбасары Елена Шулина 2015 елда эшмәкәрләргә дәүләт ярдәменең төп чаралары, республикада кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү буенча "юл картасы" һәм аның бурычлары, шулай ук иң беренче чиратта аграр бизнесны күзаллаган өстенлекле юнәлешләр турында сөйләде. Елена Юрьевна республикада сәнәгать мәйданчыкларын, инновацион инфраструктураны үстерү мәсьәләләренә дә тукталды. Сәнәгать мәйданчыкларына килгәндә, Равил Кузюров үз сәнәгать мәйданчыклары булган эшмәкәрләрнең зур перспективалары бар, диде, һәм мисалга уңышлы гына үсеп килүче "Респект-СП" оешмасын китерде.

Шулай ук катнашучылар өчен электрон каталог турындагы мәгълүмат та файдалы булды. Елена Шулина анда теркәлергә тәкъдим итте һәм: "Сезнең турында бөтен Россия беләчәк, сату-алу базары киңәячәк", – диде.

**Ахыры 2нче биттә.**

# ТОРМЫШ. КӨНКҮРЕШ

ЯШӘЕШ

## Барысы да йөрәк кушуы буенча

**Илнур һәм Роза Кәримов-Габбасовлар моннан бер ел элек кенә мизгел эчендә күпбалалы гаиләгә әверелербез дип уйламыйлар да. Уллары Раил һәм кызлары Самирадан тыш алар тагын алты балага гаилә җылысы бүләк итәләр.**

Владислав, Солтан, Алсу, Венера, Тимур, Ләйсән – бертуганнар, әти-әниләре исән булып та озак вакытлар ятим яшәгәннәр. Хәер, бер-берләре белән дә алар Илнур һәм Роза гаиләсендә генә танышканнар бит, чөнки төрлесе төрле балалар йортларына сибелгән булган. Бу гаиләдә исә үзләренә яраткан һәм кайгыртучан әти-әни, абый-апа, бабай һәм әби табалар.

– Көн саен аларның өлмаюлы күзләрен күрәм һәм тырышлыгымның юкка булмавын аңлыйм. Бәхет шул була торгандыр да инде! – ди күпбалалы әни.

Авырлыклардан сирәк кеше генә курыкмый торгандыр, һәм бик азлар гына гаиләсенә чит баланы сыендырырга әзер. Ә бу очракта сүз алты бертуган, кан-кардәш турында бара бит. Гаиләгә алганда аларның олысына 16, кечесенә нибары 3 яшь була. Яңа әти-әниләренә гаилә җылысы бүләк итү белән бергә аларны бер-берсенә якынайту өчен дә күп тырышлык куярга туры килә. Бергә җыелышкан белән генә түгел, бер-берләренә күнегергә, бер-берсен яратырга да өйрәтергә кирәк бит әле.

– Бу вакытта безнең белән нинди көчләр идарә итүен аңлатып та булмый, бары йөрәкне генә тыңладык, - дип уйларын уртаклаша Роза. – Куркыныч булды. Мин үзебез сайлаган балаларның безне кабул итүе, яратуы барыннан да мөһимрәк икәнлеген аңлый идем. Гаилә җылысына мохтаҗ балаларның видеопаспортларын караганда ни өчендер меңләгән анкета арасыннан икесенә игътибар иттем. Аларның берсендә ике, тагы берсендә өч бала турында мәгълүмат бар, әмма туганлыкларына хәтта ишарә дә юк иде. Төбәк банкы операторы бу балаларның әле эне-сеңелләре дә бар, дип хәбәр итте. Шул мизгелдә мин бу балалар кан-кардәшләрдер дип уйлап алдым, фаразым расланды. Аннан соң балаларның алтау булуы һәм аларның барысы да бер гаиләдән икәнлеге ачыкланды.

Шулай итеп, язмыш гаиләнең тормышын икегә – "бала алганчыга кадәр" һәм "аннан соң" дигән өлешләргә бүлеп куя. Кеп-кечкенә сабыйлар һәм үз яшьләренә караганда күпкә җитдиерәк күренгән үсмерләр турындагы видеосюжетлар күз алларыннан китми. Һәркайсының тормышын тулы канлы, бәхетле итәселәре килә. Чынбарлык исә алты баланы да бергә үстерү мөмкин булмавы хакында искәртеп тора. Аларга дәүләт учреждениеләрендә яшәргә язган, күрәсең. "Мондый җаваплы адымга барабыз икән инде, иң элек балалар йортларыннан китү шанслары аз булган сабыйларга ярдәм итәргә кирәк", дигән уртак фикер икесендә бер вакытта барлыкка килә. Соңгы карарны кабул итәргә исә әти-әниләре булыша. Танышырга да бергәләшеп баралар. Беренче очрашуларын әле дә дулкынлану белән искә төшерәләр.

– Ишек ачылып китте дә балалар кочагыбызга ташландылар. Сез безнең арттанмы? Безне алып китәрсезме соң? Ә син минем әнием булырсыңмы? Безнең дулкынланудан йөрәкләребез кысылды, яшьләребезне көч-хәл белән тыеп тордык. Шунда Владик сыенды да: "Ике көннән туган көнем, безне шул көнгә кадәр алып китеп өлгерерсезме?" – дип пышылдады, - дип искә төшерәләр Роза белән Илнур.

Шулай итеп, Владиславның хыялы чынга аша, ул үзенең 16 яшьлеген зур, күптән көтелгән гаиләдә каршылый. Документлар рәсмиләштерү, өйгә юл – боларның барысы да төштәге сыман. Ир белән хатын баштарак балалар түгел, ә бәлки үзләре башка җиргә яшәргә күченгән итеп хис итүләрен яшермиләр. Балаларга Нурлат кечкенә авылдан соң гаҗәеп зур шәһәр булып тоела. Адаптация чоры җиңел узса да, проблемасыз гына булмый, әлбәттә. Мәсәлән, балалар йортында уллыкка алынган сабыйларга коррекцион мәктәптә укырга дип киңәш иткән булалар, әмма Роза моның белән һич тә килешми. Монда, мөгаен, үзенең педагог-психологка укуы да йогынты ясамый калмагандыр. Даими рәвештә шөгыльләнеп торуларының да файдасы була. Өлгереш табелендәге берәр өчлене дә өченче чирек азагына 4легә төзәтәләр. Балаларның яңа дуслары барлыкка килгән, секцияләргә рәхәтләнеп йөриләр, алга таба


ЗУР ГАИЛӘ ЧӘЙ ТАБЫНЫ АРТЫНДА

балалар сәнгать мәктәбенә язылырга да ниятлиләр. Бергәләшеп төрле әйберләр, декоратив чәчәк бәйләмнәре һәм агачлар ясыйлар. Йорт яны участогын бизәү өчен дә бүгеннән әзерләнәләр инде – тәрәзә төпләрендә чәчәк үсентеләре көннәр җылытуын көтә. Балалар әниләре белән бергә аларны стаканнарга бүлеп утырталар. Яз җитү белән гаиләнең йортка ясалган янкорманың эчке эшләрен дә төгәллисе бар әле, аны узган җәй азагында төзегән булганнар. Роза белән Илнур балалар арасында татулыкның ныгый баруын, бер-берләрен кайгыртуларын күреп сөенәләр.

– Безнең балаларыбыз искиткеч, алар белән бөтен авырлыкларны җиңәргә була, - дип шатланып туя алмый ата белән ана. – Раил быел 11нче сыйныфны тәмамлый, ул хәрби һөнәр сайлады, безне яклаячак. Владислав сылаучы-буяучы булырга укый, йортлар төзү турында хыяллана. Солтан дин белән кызыксына, мәчеткә укуларга йөриячәк, безнең өчен дога кылачак. Алсуның шәфкать туташы булып кешеләрне дәвалыйсы килә. Тимурның кем буласын әйтүе кыен әле. Әмма машиналар белән мавыгуына караганда, һөнәре техника белән бәйле булыр ахрысы. Венера, Самира һәм Ләйсән кечерәкләр әле, кем буласыларын хәл итмәгәннәр. Әмма инде бүгеннән артистлык осталыклары күренеп тора. Әнә, балалар йортындагы гадәтләрен дәвам итеп, гаилә бәйрәмнәрендә концертларны ничек матур итеп оештыралар.

Роза белән Илнур күп нәрсәдә әти- әниләренең булышуын билгеләп үтәләр. Илшат һәм Җәмилә Шәрәфетдиновлар "уллыкка алынган" оныкларын шулкадәр яратканнар, аларны чит балалар дип атарга да теләмиләр хәтта. "Алар үзебезнекеләр инде. Алардан башка үзебезне күз алдыбызга да китерә алмыйбыз хәтта, - дип елмая Җәмилә Мирсәетовна. – Ярдәм итәргә ашкынып торалар! Әти-әниләренә дә булышалар, тәртип яраталар, үзара да бик татулар".

Бер ел элек үзләренә 6 баланы сыендырып Роза белән Илнур алты тормышны үзгәрткәннәр. Балаларга бүләк иткән ата-ана мәхәббәте, игелек һәм кайгырту алга таба һичшиксез сабыйларның эш-гамәлләрендә чагылыш табачак бит. Чын гаилә кыйммәтләренең нәрсә икәнлеген үзләре төрле сынаулар кичереп аңлаган балалар үз гаиләләрендә мондый язмышларның кабатланмасын өчен барын да эшләячәкләр, әлбәттә. Һәм бер-берсен ничәмә еллар үткәч эзләп тапкан туганнар беркайчан аерылмаячаклар да.

**Маргарита ЛИТТА**

ҺӨНӘРИ БӘЙРӘМ

## Очраклылык түгел бу


«ЯРАТКАН ҺӨНӘР АЛҖЫТМЫЙ»,– ДИ НАДЕЖДА ПИДПЕРИГОРА

**Апрельнең беренче якшәмбесендә Геологлар көне билгеләп үтелә.**

Барлык нефть компанияләрендә дә диярлек әлеге һөнәр ияләре бар. Мисал өчен, НПБРда – 10ау, "ТатРИТЭКнефть"тә 16ау. Ә аларның барысын да... "ТНГ-НурГИС" берләштереп тора. Әлеге предприятиеләр, районыбызның һәм аның чикләрендәге тагы берничә дистә оешма – нәкъ шул геофизиканың заказчылары.

1нче категорияле инженер-оператор Надежда Пидперигора геофизикада 38нче елын эшли инде. Ә бит башта бирегә очраклы гына килеп эләккән кебек иде. "Апамның курсташы мехматтан геофакка күчте, практикага илебезнең төрле почмакларына йөри иде, – дип сөйли Надежда Николаевна. Шуннан апасының киңәше буенча КДУның геология факультетына укырга керә дә. Һәм көткәннәре рас килә: Төньяк Двина, Памир, Алтай, Чукотка... "Искә алыр нәрсәләр бар", – дип елмая ул бүген.

Алабуга кызы Надежда Пидперигора хезмәт биографиясен 1977 елда, Бөгелмәдә геофизик булып башлый. Ә Нурлатка ире белән күчә, ул да геофизик. Шул рәвешле, Пидперигоралар 11 ел инде Нурлат геофизикасында эшлиләр.

– Эшебез кызыклы, әмма җиңел түгел, – ди Надежда Николаевна. Аның төп бурычы көн саен скважиналардан кайтарылган материалларны эшкәртүдән гыйбарәт. – Партияләр тәүлек әйләнәсе эшли, димәк, без дә заказчыларга материалны үзвакытында әзерләргә тиеш.

Шул еллар эчендә геофизикада күп нәрсәләр, иң беренче чиратта эш ысуллары үзгәрә. Надежда Николаевна диаграммаларны кулдан сызган, аларда нефть катламнарын да шул рәвешле билгеләгән, күрсәткечләрне караган, формулалар буенча санаган вакытларны да хәтерли әле. Бүген исә моның өчен заманча компьютер программалары бар, приборлар кайтып тора.

Надежда Николаевна үз һөнәре турында озак һәм кызыклы итеп сөйли ала. Димәк, геологиягә очраклы килеп эләкмәгәндер ул.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

КИҢӘШМӘ

## ГАЗДАН ФАЙДАЛАНУ ЗАКОНЛЫ БУЛСЫН

**Районда газга законсыз тоташуларга каршы көрәш дәвам итә. "Нурлатгаз" ЭПУсының шәһәрнең төзелеш-монтаж һәм сервис оешмалары катнашында үткәрелгән киңәшмәсендә сүз шул хакта барды.**

Предприятие начальнигы Рәшит Хәсәнов билгеләп үткәнчә, алар абонентларның газ челтәрләренә законсыз тоташуы һәм газны санкцияләнмәгән рәвештә куллануларын ачыклау максатыннан газ җайланмаларын һәм исәпләү узелларын тикшерү буенча чаралар үткәрәләр. Татарстанда мондый законсыз тоташулар прокуратураның игътибар үзәгенә эләккәләгән инде. Мондый очраклар бездә дә бар. Кагыйдә буларак, абонентлар суд тарафыннан зыянны мәҗбүри каплау һәм штраф түләү белән җинаять җаваплылыгына тартылалар. Баш инженер Альберт Галәветдинов кулланучыларның игътибарын мондый тикшерүләрнең даими булачагына юнәлтте. Газ челтәрләренә һәм исәпләү узеллары эшенә үзлектән катышырга тырышучы затларга карата закон кысаларында җаваплылык кулланылачак.

– Безнең максат – газны аварияләрсез бирү. Шуңа да техкарау һәм төзелеш-монтаж эшләрен сыйфатлы үткәрүгә таләпләр югары, - диде Рәшит Әхмәтҗанович.

**Валентина ВАФИНА**

# КӨН АРТЫННАН КӨН

СӘХНӘ

## Биючеләр Төньяк башкаладан кайтты

**“Эсперанса” эстрада бию ансамбленең уртанчы төркеме (җитәкчеләре Ольга Ильина) Санкт-Петербург шәһәрендә узган “Танцевальная волна” балалар һәм яшүсмерләр хореография сәнгатенең Бөтенроссия конкурс-фестиваленнән II дәрәҗә дипломант исеменә лаек булып кайтты. Коллективны туган шәһәрләрендә әти-әниләре, якыннарыннан тыш, район мәдәният бүлеге хезмәткәрләре дә каршы алды.**



Автор фотосы

“ЭСПЕРАНСА” БИЮЧЕЛӘРЕ РАЙОНДАГЫ БЕР ГЕНӘ ЧАРАДАН ДА ЧИТТӘ КАЛМЫЙ

– Безгә ышанган, көч биргән һәркемгә рәхмәт, - диләр кызлар беравыздан. – Безнең өчен бик файдалы каникуллар булды. Беренчедән, уңыш белән кайтсак, икенчедән, Россиянең тарихи шәһәренә сәяхәт бездә бик матур тәэсирләр калдырды. Узган гасыр модасы һәм мәдәнияте белән таныштык. Борис Эфман бию академиясе педагогларыннан мастер-класс алу да – биючеләр өчен иң зур бүләк ул.

Нурлатлылар “Стильләштерелгән халык биюе” номинациясендә “Кәлин, салом” (“Здравствуйте, невеста!”) номерын тәкъдим иткәннәр. Моннан тыш, яшь биючеләр А.Ваганова исемендәге рус балеты академиясендә мастер-класс та узганнар, музейларга экскурсияләргә барганнар.

– Мондый мәртәбәле конкурста, өстәвенә, яңа состав белән 2 дәрәҗә дипломга ия булу – бик зур уңыш, - ди ансамбль җитәкчесе Ольга Ильина. – Анда Россиянең төрле төбәкләреннән 720 катнашучы җыелган иде бит. Әлбәттә инде, алга таба да матур уңышларыбыз белән сөендереп торырга ниятлибез.

Моннан өч ел элек район мәдәният йорты каршында оешкан ансамбль коллективы инде 20 укучысын чыгарырга да өлгергән (шуларның икесе язмышларын хореография белән бәйләгән). Шул еллар эчендә ансамбль “Созвездие – Йолдызлык” республика яшьләр фестиваленең зона турында да призлы урыннар яулаган. Узган ел коллектив фестивальнең “Иҗади эзләнү” номинациясендә дипломга ия булган. Бүгенге көндә репертуарларында төрле милләт һәм заманча биюләрне туплаган 15ләп хореография номеры бар.

– Районда узучы бер генә чара да әлеге ансамбль чыгышыннан башка узмый, - ди район мәдәният йорты директоры урынбасары Наилә Җиһаншина. – Универсиада, республика сабантуйлары кебек зур чараларда да чыгышлар ясап торалар. Ә бу көннәрдә ансамбль янә иҗади рух белән кайнап яши. Кызлар Бөек Җиңүнең 70 еллыгына яңа бию композициясе әзерлиләр.

**Зилия ӘКСАНОВА**

### МӘГЪЛҮМАТ

“Эсперанса” эстрада бию ансамбле җитәкчесе Ольга Ильина Нурлатта 4 ел эшли. Шул еллар эчендә ТР Мәдәният министрлыгы, район башлыгы Мактау грамоталарына ия булган. Моннан тыш, ТР хөкүмәтенең перспектива буенча гранты иясе дә әле.

СПОРТ

## КОМАНДИРЛАР ЙӨЗҮЕ

**“Нурлатнефть” идарәсе спорт комплексында предприятиенең җитәкчелек составы арасындагы традицион “командирлар йөзүе” үтте.**

Бу юлы алты йөзү уздырылды. Ир-атлар да, хатын-кызлар да 50 метрлы дистанциядә ярышты. Нәтиҗәдә, 35 яшькә кадәрге хатын-кызлар арасында иң көчлесе кадрлар бүлеге начальнигы Лилия Сәмигуллина булды, 35 яшьлек һәм аннан өлкәнрәкләрдән финанс бүлеге начальнигы Марина Кармухинаны уза алучы табылмады. 40 яшькә кадәрге ир-атлар арасында I урынны идарәнең баш инженеры Равил Әхмәдиев яулады, 40-50 яшьлекләрдән нефть чыгару буенча производство бүлеге начальнигы Рөстәм Хәбибуллин, 50-60 яшьлекләр арасында профком рәисе Ринат Мөхәммәтҗановка тиңнәр табылмады. Ярышлар 60 яшьлек һәм аннан да өлкәнрәк ир-атларның йөзүе белән тәмамланды. Биредә идарә начальнигы Илгиз Салихов җиңде.

Ярышларны ябу тантанасында Илгиз Салихов матур корпоратив традицияне хуплаганнары һәм ярышларда актив катнашканнары өчен барлык командирларга да рәхмәтен белдерде. Җиңүчеләргә һәм призерларга грамоталар, акчалата бүләкләр тапшырылды.

**Марина КОРНИЛОВА, “Нурлатнефть” НГДУсы**

## ТРАНСПОРТЧЫЛАР КӨРӘШКӘ ЧЫКТЫ

**Узган атнада Нурлат УТТсы командасы Әлмәттә “Татспецтранспорт” компаниясе спартакиадасының милли көрәш төрендә катнашып кайтты.**

Идарәнең шоферлары, тракторчылары спорт белән бик дус икәнлекләрен тагы бер тапкыр исбатладылар. Алар бу юлы да призлы урыннар белән кайттылар. Мисал өчен, инженер-энергетик Марсель Гозәеров һәм шофер Айдар Ишниязов үз үлчәү категорияләрендә җиңүче исемнәре яуладылар. Автокран машинисты Илназ Зәйнетдинов III урын алды. Шулай ук команданың башка спортчылары – экскаватор машинисты Сирин Хәмидуллин һәм тракторчы Илдар Сөнгатуллин да матур көрәш күрсәттеләр. Гомумкоманда нәтиҗәләре буенча, Нурлат УТТсы II урынга чыкты.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

ПРОКУРАТУРА ХӘБӘРЛӘРЕ

## КИБЕТ АКЧАСЫН ТУЗДЫРГАН

**Нурлат шәһәр прокуратурасы тикшерү тарафыннан бер нурлатлыга карата РФ ҖКның 160нчы маддәсе 1нче өлешендә (гаеплегә ышанып тапшырылган чит милекне үзләштерү яки туздыру, ягъни урлау) каралган җинаять кылуда билгеләнгән гаепләүне хуплады.**

Суд утырышында бер нурлатлының 2013 елның 12 ноябреннән 2014 елның 31 гыйнварена кадәрге чорда җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьтә сәүдә вәкиле булып эшләп, җәмгыятьнең 162 мең сумнан артыграк акчасын үзләштерүе расланды.

Суд утырышында гражданинның гаебен йомшартырга ярдәм итүче фактлар – кече яшьтәге баласы булуы һәм гаебен тулысынча тануы исәпкә алынды һәм җәза штраф рәвешендә билгеләнде.

**Евгений СЕРГЕЕВ, Нурлат шәһәр прокуратурасы**

## САЙТКА КУЯРГА “ОНЫТКАННАР”

**Нурлат шәһәр прокуратурасы “Уютный дом” идарәче компаниясендә торак законнары таләпләренең үтәлешен тикшерде.**

Тикшерү барышында идарәче компаниянең, гамәлдәге законны бозып, Интернет челтәрендәге сайтында “Уютный дом” ИК җәмгыятенең директорын административ җаваплылыкка тарту очрагы турында мәгълүматны урнаштырмавы ачыкланды. Шулай итеп, директор прокурорның 2014 елның 14 февральдәге һәм 16 октябрьдәге карарлары нигезендә, торак йортларны һәм торак биналарны карап тору һәм ремонтлау кагыйдәләрен бозуы өчен административ җаваплылыкка тартылды.

**Яков ВЛАСОВ, Нурлат шәһәр прокуратурасы**

КЫСКА ХӘБӘРЛӘР

## ЭШ ТӘҖРИБӘСЕ КЫЗЫКСЫНДЫРА

**Узган атнада Нурлат районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Әлфия Галәветдинова җитәкчелегендә районда гы рус, үзбәк, татар, чуваш милли берләшмәләре вәкилләре Түбән Кама шәһәренең Халыклар Дуслыгы йортында булып кайттылар.**

Нурлатлыларны Дуслык йорты директоры Васыйл Харисов үзе кабул итеп, йортта һәр милли берләшмә өчен тудырылган мөмкинлекләр белән таныштырды, эш тәҗрибәләре турында сөйләде. Шунда ук биредә тупланган 10 милли берләшмә җитәкчеләре белән дә очрашу булды. Сүз уңаеннан, аңа кадәр нурлатлылар Казандагы Халыклар Дуслыгы йортының эш тәҗрибәсе белән танышып кайтканнар иде инде. Сәфәрләр район башлыгы Равил Кузюров тәкъдиме белән үзебездә Халыклар Дуслыгы йортын ачуга әзерлек кысаларында оештырылды.

**Сәкинә ХӘЙРУЛЛИНА**

## МАХСУС КҮРГӘЗМӘ

**Үзәк китапханәнең хокукый мәгълүмат үзәге районның җир иясләре һәм җирдән файдаланучылары өчен “Җир мөнәсәбәтләре: закон һәм практика” исемле махсус күргәзмә әзерләде.**

Анда гади гражданинга кагылышлы төп закон актлары белән танышырга була. Бу – аңлатмалары белән РФ Җир кодексы да, җирдән файдалану, бакчачылык һәм дача берләшмәләре турындагы законнар да.

– Иң кирәкле мәгълүматны түләүсез алу, чыганаклар белән танышу өчен нурлатлылар безнең үзәккә килә ала. Чөнки җиргә бәйле сораулар һәр кешедә туарга мөмкин. Бу очракта законда күрсәтелгән гадәти нормалар һәм кагыйдәләрне белү зур проблемаларга юлыкмаска булыша, – диләр китапханә хезмәткәрләре.

**Маргарита ЛИТТА**

## БӘЙРӘМ УЙНАП ҮТТЕ

**Районның 300дән артык мәдәният хезмәткәре быел үзләренең һөнәри бәйрәмнәрен Якты Күл авылы мәдәният йортында конкурс-уен формасында үткәрделәр.**

Аларны һөнәри бәйрәмнәре белән район башкарма комитеты җитәкчесенең яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге җитәкчесе Әнәс Нәбиуллин, Яңа Иглай авылы җирлеге башлыгы Гүзәлия Лотфуллина котладылар. Шунда ук бер төркем актив хезмәткәрләргә ТР Мәдәният министрлыгының, Нурлат муниципаль районы башлыгының һәм район мәдәният бүлегенең Мактау грамоталары тапшырылды.

– Быел традицон концерт формасыннан бераз тайпылырга булдык, - ди район мәдәният йорты директоры урынбасары Наилә Җиһаншина. – 4 командага бүленеп “Пират кичәсе” дип аталган конкурс үткәрдек. Уенда иң көчлеләр дип “Яшен” командасы табылды.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## ТӨШКЕ АШ ФАЙДАГА БУЛДЫ

**“Гармония” үзәгенең гаиләгә һәм балаларга ярдәм күрсәтү бүлегендә патронатта торучы балалар каникуллар чорында “Мистер Бургер” кафесында хәйрия төшке ашында булып кайттылар.**

Тәм-томнар белән сыйланудан тыш, балалар спорт-күңел ачу комплексында да актив ял иттеләр. Үзәкнең социаль педагоглары һәм психологлары төрле занятиеләр әзерләгән иде. “Ура, каникуллар” анимацион уены һәм “Театр сәнгате” өйрәтү семинары да балаларда зур кызыксыну уятты. Алар әкият театры һәм мультфильмнар дөньясына чумдылар. Иҗат җимешләрен үзләре үк сәхнәгә куйдылар, сценарияләрен яздылар һәм тамаша да кылдылар. Дәресләр күңел ачудан тыш, профориентация элементларын да үз эченә алды. Балалар яңа, билгеле булмаган һөнәрләр турында ишеттеләр.

**Светлана ИЛЬИНА**

